ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы законнары мониторингы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 11 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы законнары мониторингы турында» 2010 елның 3 июлендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 10) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 статьяның 2 өлешендәге 5 пунктында «гамәлдәге» сүзен төшереп калдырырга;

2) 9 статьяда:
а) 2 өлешнең 2 пунктында «гамәлдәге» сүзен төшереп калдырырга;
б) 4 өлешнең 2 пунктындагы «г» пунктчасында «максатчан» сүзен «дәүләт» сүзенә алмаштырырга;

3) 11 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 4 һәм 5 пунктлар өстәргә:
«4) законга коррупциягә каршы экспертиза үткәрү турында белешмәләр;
5) әзерләве һәм кабул ителүе законда каралган кабул ителгән норматив хокукый актлар хакында белешмәләр.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2020 ел, 25 июнь
№ 30-ТРЗ